**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2022елның 10 октябре** **81-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына генераль планны әзерләү кирәклеге булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9,20,21 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерелгән 2022 елның 26 сентябрендәге 10-53/11722 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына (кушымталар нигезендә) уңай бәяләмә нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Советының 2011 елның 19 декабрендәге 117-ТР номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына, кушымта нигезендә, түбәндәге торак пунктларның чикләре турында белешмәләр өстәү өлешендә әлеге кararга кертергә:

- Александровка авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Югары Кармачы авылы, Түбән Кармачы поселогы;
- Атабай авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Атабай авылы;
- Көек авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Алексеевск поселогы, Көек авылы;
- Кече Елга авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Кече Елга авылы.

2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында да https://fgistp.economy.gov.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**